ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2020 с.Старое Дрожжаное № 290

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 июнендәге 271 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив актларны «Ана (гаилә) капиталы чаралары белән эш итүгә бәйле мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 01 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 июнендәге 271 номерлы карары белән расланган «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» **6 нчы кушымтасына** түбәндәге эчтәлекле 29.1 пунктчасы белән **1 нче кушымтаны** өстәп, үзгәреш кертергә:

«29.1) дәүләт яисә муниципаль милектә булган балыкчылык кишәрлегеннән файдалану шартнамәсе нигезендә товар аквакультурасын (товар балыкчылыгын) гамәлгә ашыручы затка әлеге максатлар өчен җир кишәрлеге бирү;».

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 июнендәге 271 номерлы карары белән расланган «Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 27 нче кушымтага, **2.5 пунктының 7 пунктчасын төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.**

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов